Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнар җыены

---

# КАРАР

«18» октябрь 2024 ел № 4

2025 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
Тойгуҗа авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнар җыены **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасындагы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, мобилизацияләнгәннәрдән һәм махсус хәрби операциягә контракт буенча китүчеләрдән  һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

«1. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Тойгуҗа авылы скважинасы өчен 1 (бер) данә насос сатып алу).
2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (комплектта янгын гидранты сатып алу; Тойгуҗа авылында янгын гидранты урнаштыру).
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү: (Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабу).»

3. . Әлеге карарны мәгълүмат стендларында  урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru “Тойгуҗа авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
ТР Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сафин